**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**10 октябрь 2019 ел** **№ 240**

**Нурлат муниципаль районы Советының «Нурлат муниципаль районы муниципаль хезмәте турындагы нигезләмәне раслау турында»гы 2019 елның 18 июнендәге 219 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында» 2013 елның 25 июнендәге 50 - ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, «Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турында» һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы, **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль хезмәте турында Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 18 июнендәге 219 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль хезмәте турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 бүлегенең 3.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Районда муниципаль хезмәт Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы кодексы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, муниципаль берәмлек уставы, әлеге Нигезләмә, башка муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.».

1.2. Нигезләмәнең 7 бүлегенең 7.4 бүлегендәге 6 пунктчасында «хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы» сүзләрен «индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ, шул исәптән электрон документ формасында да» сүзләренә алмаштырырга;».

1.3. 13.3 пунктның икенче абзацында. "Ә стажның озынлыгы һәм айлык түләүләр «Муниципаль хезмәт турында» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен билгеләгәндә муниципаль хезмәткәргә билгеләнгән шундый ук күләмнәрдә исәпкә алына.» сүзләрен «ә класс чины өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләү

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларын билгели торган норматив хокукый актында билгеләнгән мәгънәдә исәпкә алына.» сүзләре белән алмаштырырга.

1.4. Нигезләмәнең 21 бүлегенең 21.10-21.13 пунктларын яңа редакциядә бәян итәргә:

«21.10. Контракт буенча район Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм әлеге вазыйфаны башкаручы зат, Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) белешмәләр тапшыралар.

21.11. Район Башкарма комитеты җитәкчесенең контракт буенча вазыйфасын биләүче зат тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирле үзидарә органының рәсми сайтында урнаштырыла һәм (яки) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирелә.

21.12. Әлеге нигезләмәнең 21.10 пункты нигезендә билгеләнә торган керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының югары вазыйфаи заты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) карары буенча гамәлгә ашырыла.

21.13. Әлеге бүлекнең 21.12 пункты нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм булу, кулдагы акчаларны һәм кыйммәтләрне саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалану тыелу турында» 7 май, 2013 ел, № 79-ФЗ Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү фактларын ачыклаганда, Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты - район Башкарма комитеты җитәкчесе депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты тарафыннан яисә күрсәтелгән затларга карата тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка бүтән җаваплылык чараларын куллану турында гариза белән мөрәҗәгать итә.».

1.5. Нигезләмәнең 34 бүлегенең 34.2 пунктындагы «Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән исемлеге билгеләнә торган дәүләт яисә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән граждан белән хезмәт шартнамәсе төзегәндә эш бирүче тарафыннан мондый шартнамәне төзү турында дәүләт яисә

муниципаль хезмәттән азат ителгәннән соң 2 ел дәвамында аның соңгы хезмәт урыны буенча эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленә (эш бирүчегә) һәм муниципаль хезмәткәргә хәбәр итү тәртибе турында;» сүзләрен «Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән исемлеге билгеләнә торган дәүләт яисә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән граждан белән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яисә граждан-хокукый шартнамәсен төзү турында эш бирүче тарафыннан хәбәр итү кагыйдәләрен раслау хакында «2015 елның 21 гыйнварындагы 29 номерлы Хөкүмәт карары белән» сүзләренә алмаштырырга».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы рәисе А.С. Әхмәтшин